# НИ ХӘЛЕҢ БАР, ӘНИ?

**Хәзер туганлыкның да сүзе генә бар кебек. Тормыш сынавы белән күзгә-күз очрашканда, кемнәндер ярдәм көтәм димә, һәркемнең үз мәшәкате, үз тормышы. Тик күңел бары җылы сүз, яхшылык көтеп яши...**



pixabay.com

Галимә әби күршесенең моң-зарларын тыңлап утырды да, бераз бүленеп алыйк дип, чәй куярга чыгып китте. Көн саен ахирәте кердә дә, туганлык җебе турында сөйләп, авырткан җиренә тоз сала. Галимә ул әйтмәсә дә белә бит аны, нигә һаман исенә төшереп торырга? Кичә генә 80 яшьлек юбилеен гөрләтеп уздырдылар, аны котларга Мәскәү хәтле Мәскәүдән уллары, оныклары кайткан иде. Барысы да бер табынга җыелыштылар да, «Сүзне кемгә бирик?» дигәндәй, аптырап калдылар. Төп нигездә яшәүче малае Хәбир тамак кырып алды да әнисе Галимә янына килде.

– Менә, әни, бүген барыбыз да сине хөрмәт итеп, яратып, шушы түгәрәк өстәлгә җыелдык. Син булмасаң, беребез дә үз юлыбызны таба алмас идек. Еракта яшәүче улларың да, бар эшләрен ташлап, туган йортка кайттылар. Оныкларың да «Дәү әни!» дип өзелеп торалар.

Хәбире бигрәк нечкә күңелле булып үсте, тост әйтәм дип баскан җирендә дә ике җөмләсендә күз яшен сөртте. Аннары сүзгә Галимәнең ике улы, бер кызы да кушылды. Дүрт нарасыен күз карасы кебек карап үстергән ананың бүген урыны түрдә иде. Ләкин күңеле генә нидер эзләнде, туганнарының җылылыгын тоймады. Бәйрәмнән соң кич белән ишегалдында самавыр кайнаттылар, шашлык пешерделәр. Дәртле көйләргә күңел ачтылар. Галимә тамагын туйдырып, тәлинкәсен аш бүлмәсенә алып керим дигәндә, киленнәренең «күңелле» сөйләшүенә туры килде. Мәскәү килене белән Казандагы Рәхимәсенең савыт-саба юып маташуы иде.

– Әнкәй бигрәк беркатлы инде безнең, әйеме? Үзенең юбилеен үткәрергә кайттык дип уйлыймы икән әллә ул? Мин, мәсәлән, аның кесәсен бераз бушатырга кайттым – һич акча җиткереп булмый.

– Син генә түгел, үзем дә иремне шуңа әйдәләдем. Минәйтәм, әниеңне котламыйча булмас, бердәнбер газиз анаң бит ул синең дидем.

– Уллары да үзе кебек инде, тор дисәң – тора. Үзләре бер эшне дә без әйтмичә эшли белмиләр.

– Каннан күчкәндер инде, Рәхимә.

Икесе дә шаркылдап көләргә тотындылар. Берсенең кулындагы тәлинкәсе идәнгә төшеп ватылды. Галимә, йөрәген тотып, диванга барып ятты, бар көченә: «Су!» – дип кычкырды. Ишегалдыннан килгән көчле музыка, аш бүлмәсендәге киленнәрнең сөйләшүе, бүлмәләрдә телефон уенына чумган оныкларының чырык-чырык көлүләре Галимәнең тавышын каплады. Карчык якындагы пыяла вазаны аударды. Чәлпәрәмә килгән тавышка Рәхимәсе йөгереп чыкты. Беренче итеп әнкәсенә түгел, ваза кыйпылчыгына карады:

– Безнең бүләк харап булган! Әнкәй, нишләттең инде?

Галимә, йөрәген тоткан килеш: «Су», – дип кабатлавын дәвам итте. Залга икенче килен очып чыгып җитте:

– Рәхимә, диван янына куясы түгел бит инде андый бүләкне. Әнкәйнең холкын беләсең, – дип, үзенчә киңәшен бирде.

Ишектән кергән Хәбир «Шашлык пеште!» диярге дә өлгермәде, әнисен күтәреп алып, ишегалдына йөгерде. Гадәттә, Галимәне шәфкать туташына алып төшә иде ул. Бу юлы да карчыкны укол гына коткарып калды. Өйдәгеләр Хәбирнең кайтуын дүрт күз белән көттеләр. Барысы да әниләре өчен борчылган йөз ясаганнар иде. Әнисен бүлмәсенә кертеп яткыргач, Хәбир аш бүлмәсенә чәйләп алырга кереп китте. Аның артыннан, аяк очына гына басып, калганнар да иярде.

– Сез, – диде Хәбир, бар батырлыгын җыеп. – Нәрсәгә кайттыгыз соң монда? Әнинең юбилеен бәйрәм итәргәме, әллә инде шушы диванына яткырып, соңгы васыятен тыңларгамы? Күрәм, барыгыз да ишле, икешәр-өчәр балагыз бар. Акчагыз да кесәгез тулы. Ә йөрәк дигән җирегездә әнигә булган хөрмәт хисе яшиме сезнең? Ул безне – дүрт баланы әтисез, берүзе үстерде, утка-суга да безнең өчен керде. Шушы нигездәге йортны да авыл халкы ярдәме белән төзетте. Хәер, сезгә нигез турында сөйләп мәгънә юктыр. Сез бит бу йортны елына бер – әнинең туган көнендә яисә пенсия алган вакытында гына кайтып күрәсез. Ә мин көн саен әнинең авыртудан ыңгырашып, су сорагагынын ишетәм. Аңа сезнең кыйбатлы күлмәк, бүләгегез кирәкми, бары тик җылы сүзегез, игътибарыгыз гына кирәк, туганнарым.

Хәбир алдан әзерләгән сүзләрен әйтеп бетермәде, күзен каплап, әнисе янына кереп китте. Өстәлдәге салкын чәен Рәхимә түгеп, яңаны ясады. «Әнигә чәй китерим әле», – дип ана янына ашыкты, ә икенче килене бүлмәләрне җыештырып алырга булды. Шау-гөр килгән балалар да, телефоннарын читкә куеп, урамдагы күрше балалар белән танышырга чыгып киттеләр. Галимә бит балалары белән менә шундый тату тормышны күптәннән күрергә хыялланган иде. Ләкин тиран йокысына талып, аны да төшендә генә күрде.

Икенче көнне балалары үз өйләренә кайтып киттеләр. Өйдә бары тик тынычлык һәм Галимә белән Хәбир генә калды.

– Әни, бик ерakka чыгып йөрмә инде, яме? Күршеләр дә үзләре монда керсен. Хәлең бик яхшыдан түгел бит, – диде улы, күрше ахирәте кергәнен күреп.

– Син хәлемне сорап торганда яшәргә була әле, балам, – диде Галимә, өмет тулы күзе белән улына карап...

**Рәфидә ГАЛИМҖАНОВА.**

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# КАССА ЧЕГЫ: БИРЕРГӘМЕ-ЮКМЫ?

**?**


**«Кайбер кечкенә сәүдә предприятиеләрендә (кибесенчә, базарда) сатып алучыларга касса чегы бирүдән баш тарталар. Һәм моны «безгә закон буенча касса аппаратыннан башка сәүдә итәргә рөхсәт бар» дип аңлаталар. Күптән түгел Казан базарларының берсендә балык сатып алдым – карап торышка ашарга яраклы кебек, әмма өйдә бер тапкыр кисеп җибәрүгә үк «шартлады», чөнки газ белән тулган иде. Сатучы акчаны кайтарып бирүдән баш тартты: янәсе, сез бу балыкны миннән сатып алмадыгыз, мин сезне хәтерләмим. Касса чегы бөтен җирдә дә мәҗбүри түгелмени?**

**Р.Тәхвәтуллин».**

**Әлеге сорауга ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге башлыгы Розалия Арсланова җавап бирә:**

– Владимир Путин «Россия Федерациясендә исәп-хисап ясаган вакытта контроль-касса техникасын куллану хакында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль канунны имзалады. Ул 2019 елның 6 июнендә үз көченә керде. Әлеге закон торак-коммуналь хуҗалык (ресурс белән тәэмин итү оешмалары хезмәтләрен дә кертеп), сак һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү системалары, мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәткәндә контроль-касса техникасын куллануны гадиләштерүне күздә тота. Моннан тыш, кулланучыларга исәп-хисап ясый торган урыннан читтә урнашкан контроль-касса техникасын товарны дистанцион алым белән сатканда, берәр төрле эш башкарган урында һәм сәүдә объектыннан читтә хезмәт күрсәткән вакытта, шулай ук шофер яки кондуктор тарафыннан транспорт чарасы салонында исәп-хисап ясаганда, торак-коммуналь хезмәтләре өчен түләүләр кабул иткәндә файдалану хокукы бирелә. Әлеге очракларда касса чегы кәгазьгә чыгарылмаска, ә QR-кодны күрсәтеп тәкъдим итепләргә мөмкин.

Федераль закон тарафыннан контроль-касса техникасы кулланылмый торган очраклар төгәлләк кертелә. Әйтик, бахилларны әлеге техникадан башка гына сатарга мөмкин. Онлайн-режимында түләгәндә торак милекчеләре ширкәтләре, мәгариф, спорт һәм мәдәният оешмаларына; кулдан яки лотоктан театр билетлары саткан вакытта контроль-касса техникасыннан башка эшләргә рөхсәт ителә.



Мәгариф, сак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендәге хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан алдан башкарылган түләүләр һәм (яки) авансларны исәпләү яисә кире кайтару рәвешендә исәп-хисап ясаган вакытта бер айдан да артмаган чорга шундый исәп-хисапларның барысы турында да мәгълүмат урын алган бер чек формалаштырылачак. Чекны формалаштыру вакыты 1 көннән 10 көнгә кадәр озайтылган.

Ялланган хезмәткәрләре булмаган һәм үзләре җитештергән товарларны сатучы яки хезмәт күрсәтүче шәхси эшкуарлар 2021 елның 1 июленә кадәр контроль-касса техникасыннан башка гына эшли ала.